ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.07.2022 г.Лениногорск № 688

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 маендагы 516 номерлы «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Сугышлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Сугышлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә кушу рәвешендә һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе – балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә үзгәртеп оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә бюджет

акчаларын тотуны оптимальләштерү максатларында, Россия Федерациясе Граждан кодексының 57 - 59 статьяларына, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясына таянып, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 маендагы 516 номерлы «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Сугышлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Сугышлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә кушу рәвешендә һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе – балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә үзгәртеп оештыру турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«Сугышлы башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе – балалар бакчасы» аңа кушылучы ТР «ЛМР» муниципаль берәмлеге «Сугышлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе»нең хокуклары һәм бурычлары буенча хокукларын кабул итүче булып тора дип билгеләргә.

5 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп кору турында ата-аналарга (законлы вәкилләренә) хәбәр итәргә һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Сугышлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Сугышлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә кушу рәвешендә үзгәртеп корылган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе – балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең ( алга таба - ТР «ЛМР» МБ «Сугышлы башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе – балалар бакчасы») хокуклары һәм бурычлары буенча хокукларын кабул итүче булып торуы турында хәбәр итәргә.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://leninogorsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль

бирәмлеге Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы В.С. Санатуллинга йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

В.С. Санатуллин
5-12-22